СОВЕТ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

19.04.2021 с. Сарманово № 29

«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Сарман муниципаль районы Советы карары хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 20 июлендәге 236-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 31 июлендәге 263-ФЗ номерлы, «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәве турында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 44 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 8 декабрендәге 411-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына янгын куркынычсызлыгы өлкәсендәге эшчәнлекне камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 22 декабрендәге 454-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына алкоголь, наркотик яисә башка токсик исерек хәлдәге затларга ярдәм күрсәтү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 29 декабрендәге 464-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Сарман муниципаль районы Советы карар итте:

1. «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Сарман муниципаль районы Советы карары проектын (1 нче кушымта) килештерергә һәм ачык тыңлауларга чыгарырга.

2. Расларга:

– Сарман муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты буенча гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе (2 нче кушымта);

– Сарман муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр

кертү турында» карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү тәртибе (3 нче кушымта).

3. «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Сарман муниципаль районы Советы карары проекты буенча кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эшче төркем төзергә:

1) Камалетдинов И. Н. - төркем җитәкчесе;

2) Гыйльфанов Ф. М. – төркем әгъзасы;

3) Фатыйхов Ш. М. - төркем әгъзасы;

4) Билалова А. И. - төркем әгъзасы;

5) Гайсин Р. М. - төркем әгъзасы

4. Сарман муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты буенча - Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Советының утырышлар залында (Сарман авылы, Ленин урамы, 35 йорт) халык алдында тыңлаулар үткәрергә.

5. Эшче төркемгә Сарман муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты буенча тәкъдимнәрне өйрәнергә һәм гомумиләштерергә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Сарман муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карары проекты буенча кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эшче төркемгә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Советы Рәисе

Ф. М. Хөснуллин

Сарман муниципаль районы Советының
_________елның ___номерлы карарына
1 нче кушымта

**«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 20 июлендәге 236-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 31 июлендәге 263-ФЗ номерлы, «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәве турында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 44 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 8 декабрендәге 411-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына янгын куркынычсызлыгы өлкәсендәге эшчәнлекне камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 22 декабрендәге 454-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына алкоголь, наркотик яисә башка токсик исерек хәлдәге затларга ярдәм күрсәтү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 29 декабрендәге 464-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Сарман муниципаль районы Советы карар итте:

1.Кушымта нигезендә «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

2. Әлеге карар гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә үз көченә керә.

3. Әлеге карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә җибәрергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль район Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы Советы Рәисе Ф. М. Хөснуллин

Сарман муниципаль районы Советының
_________елның ___номерлы карарына
кушымта

**«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

1 ) 7 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 15 пункт өстәргә:
15) участок полициясенең вәкаләтле вазыйфасын биләгән хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына хезмәткәр тарафыннан күрсәтелгән вазыйфаны биләү чорында торак урыны бирү.»;

2) 7 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 16 пункт өстәргә:
«16) алкоголь, наркотик яки башка токсик исерек хәлдә булган затларга ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру.

3) 7 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 17 пункт өстәргә:
«17) муниципаль янгын сагы булдыру.".

4) 17 статьяның 1 өлешен "җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары турында" сүзләреннән соң "инициативалы проектларны кертү һәм аларны карау мәсьәләләре буенча фикер алышу" сүзләрен өстәргә;

5) 19 статьяның 2 өлешенә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Гражданнарның инициативалы проектка ярдәм итү турындагы фикерен ачыклау мәсьәләсе буенча гражданнардан сорау алуда инициативалы проектны гамәлгә ашыру тәкъдим ителгән муниципаль берәмлек яки аның өлешендә уналты яшькә җиткән яшәүчеләр катнашырга хокуклы.»;

6) 19 статьяның 3 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:
«3) инициативалы проектны гамәлгә ашыру тәкъдим ителә торган муниципаль берәмлек яисә аның өлешендә уналты яшькә җиткән яшәүчеләрнең әлеге инициативалы проект турында гражданнарның фикерен ачыклау өчен.»;

7)19 статьяның 5 өлеше беренче абзацында «Муниципаль район советы белән. Муниципаль район органы карарында» сүзләрен «муниципаль берәмлек органы белән» сүзләренә алмаштырырга. Гражданнар арасында сорау алу үткәрү өчен "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Сарман муниципаль районының рәсми сайтында https://sarmanovo.tatarstan.ru/index.htm веб адресы буенча файдаланырга мөмкин. Нормативта";

8) 19 статьяның 5 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 6 пункт өстәргә:
«6) Сарман муниципаль районының "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтыннан файдаланып, сорау алуда катнашучыларны https://sarmanovo.tatarstan.ru/index.htm веб-адрес буенча идентификацияләү тәртибе.

9) 19 статьяның 7 өлешендәге 1 пунктына " яисә муниципаль берәмлек халкын" сүзләрен өстәргә;

10) 43 статьяның 2 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 14,15,16 пунктлар өстәргә:
«14) муниципаль янгын сагы булдыру.»

15) участок полициясенең вәкаләтле вазыйфасын биләгән хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына хезмәткәр тарафыннан күрсәтелгән вазыйфаны биләү чорында торак урыны бирү.»
«16) алкогольле, наркотик яки башка токсик исерек хәлдә булган затларга ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру.».

11) 78 статьяның 3 өлешен үз көчен югалткан дип санарга.

12) 88 статьяның 2 өлешендә «аны» сүзен төшереп калдырырга, «Муниципаль берәмлек уставы турында белешмәләр кертү хакында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясындагы 6 өлешендә каралган муниципаль берәмлек уставы, муниципаль хокукый акт турында белешмәләр, Россия Федерациясе субъекты муниципаль берәмлекләре уставларының дәүләт реестрына үзгәрешләр кертү хакында хәбәрнамәне» сүзләрен өстәргә.

Сарман муниципаль районы Советының
_________елның ___номерлы карарына
2 нче кушымта

**Сарман муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү һәм аның турында фикер алышуда гражданнарның катнашуы турында» карары проектына карата гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе**

1. Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проектына тәкъдимнәр Татарстан Республикасы, Сарман муниципаль районы, Сарман авылы, Ленин урамы, 35 йорт адресы буенча Сарман муниципаль районы Советына язмача кертелә.

Тәкъдимнәр эш көннәрендә махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларда халыкка җиткерелгәннән соң 30 көн эчендә 08:00 сәгатьтән 16:00 сәгатькә кадәр кабул ителә.

2. Ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризалар Татарстан Республикасы, Сарман муниципаль районы, Сарман авылы, Ленин урамы, 35 йорт адресы буенча яисә почта аша (конвертта «Устав турында фикер алышу» дигән тамга белән) тапшырыла.

Гаризалар ачык тыңлаулар үткәрү датасына кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча эш көннәрендә 08:00 сәгатьтән 16:00 сәгатькә кадәр кабул ителә.

Сарман муниципаль районы Советының
_________елның ___номерлы карарына
3 нче кушымта

**Сарман муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү тәртибе**

1. Сарман муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты буенча халык алдында тыңлаулар (алга таба - ачык тыңлаулар) «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 16 статьясы нигезендә үткәрелә.

2. Ачык тыңлауларда катнашучылар, үз тәкъдимнәрен аргументлау өчен чыгыш ясау хокукы белән, ачык тыңлаулар үткәрү датасына 7 көннән дә соңга калмыйча язма гаризалар тапшырган җирлек халкы катнаша.

3. Ачык тыңлауларда халык алдында чыгыш ясау хокукыннан башка, җирлекнең барлык кызыксынган кешеләре дә катнаша ала.

4. Катнашучыларны теркәү ачык тыңлаулар башланганчы 30 минуттан алда башлана.

5. Ачык тыңлауларда район Башлыгы рәислек итә.

6. Ачык тыңлаулар рәислек итүченең кереш сүзе белән ачыла, ул утырышта катнашучыларга фикер алышына торган мәсьәләнең асылы, тыңлауларны үткәрү тәртибе турында хәбәр итә.

7. Беркетмәне рәсмиләштерү, кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу өчен рәислек итүче тәкъдиме буенча секретариатның җитәкчесе һәм ике әгъзасы составында ачык тыңлаулар секретариаты сайлана.

8. Төп доклад белән Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Советы карары белән вәкаләтле Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Советы депутаты чыгыш ясый.

9. Ачык тыңлауларда катнашучылар, чыгыш ясау хокукы белән, гариза бирү вакытына карап, чират тәртибендә үз тәкъдимнәрен аргументлау өчен чакырыла.

10. Ачык тыңлауларда катнашучыларның чыгышлары 5 минуттан артык дәвам итәргә тиеш түгел.

11. Ачык тыңлауларда катнашучылар чыгыш тәмамланганнан соң чыгыш ясаучыларга рәислек итүче рөхсәте белән сораулар бирергә хокуклы.

12. Ачык тыңлауларда катнашучылар ачык тыңлаулар барышында аларны туктатырга һәм үткәрүгә комачауларга хокуклы түгел.

13. Ачык тыңлаулар уздырганда тәртипне үтәү ачык тыңлауларда катнашу өчен мәҗбүри шарт булып тора.

14. Катнашучылар ачык тыңлаулар үткәрү тәртибен бозган очракта, рәислек итүче аларны утырыш залыннан чыгаруны таләп итәргә хокуклы.

15. Чыгышлар тәмамланганнан соң, рәислек итүче ачык тыңлаулар секретариаты җитәкчесенә ачык тыңлаулар барышында әйтелгән тәкъдимнәрне ачыклау өчен сүз бирә ала.

16. Ачык тыңлауларда катнашучыларның барлык кисәтүләре һәм тәкъдимнәре секретариатка язма рәвештә тапшырыла һәм ачык тыңлаулар беркетмәсенә кушыла. Ачык тыңлаулар беркетмәсенә рәислек итүче кул куя һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Советы материалларында саклана.

17. Ачык тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә эшче төркем тарафыннан әзерләнә.

18. Ачык тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә халыкка җиткерелергә тиеш.

19. Ачык тыңлаулар үткәрүне оештыру һәм матди-техник яктан тәэмин итү Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Советы тарафыннан гамәлгә ашырыла.